| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет<br>Большенуркеевского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | | Татарстан<br>Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Зур Нөркәй<br>авыл җирлеге<br>башкарма комитеты |
|---|---|---|

КАРАР

12 декабрь 2018 ел № 11

Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 10 августында кабул ителгән 6 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата тулы керемнәре турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

28.12.2013 ел, № 400-ФЗ «Иминият пенсияләре турында» гы Федераль закон нигезендә, Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 10 августында кабул ителгән 6 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата тулы керемнәре хакында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 кушымтаның 2 пунктындагы 2 абзацын «картлык буенча хезмәт пенсиясе» сүзтезмәсен «картлык буенча иминият пенсиясе»дигән сүзтезмәгә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә, шулай ук мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма
комитетының җитәкчесе Р.М.Гайсин